# КАРАР

**26 ноябрь, 2019 ел** **№2**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Филипповка бистәсендә янгынга каршы кое урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Филипповка поселогында насос алу;
- Филипповка бистәсе юлларын кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 63 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 60 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80

яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, күп балалы гаиләләр һәм туендыручысын югалткан гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Филипповка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Филипповка бистәсендә янгынга каршы кое урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Филипповка поселогында насос алу;
- Филипповка бистәсе юлларын кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья Авыл Җирлеге Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы М.М. Егорова